| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2021 г. Заинск № 99

**Зәй муниципаль районы һәм аның составына керә торган авыл җирлекләре шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы нигезендә, шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслауга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы һәм аның составына керә торган авыл җирлекләре шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының икътисади үсеш, экология, табигый ресурслар һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г.Кәримов**

Зәй муниципаль районы Советының 25 август 2021 ел 99 номерлы карарына кушымта

**Зәй муниципаль районы һәм аның составына керә торган авыл җирлекләренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында нигезләмә**

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге нигезләмә Зәй муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертүнең тәртибен билгели.

1.2. Зәй муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары (алга таба - җирле нормативлар) җирлекләрне электр һәм газ белән тәэмин итү, муниципаль район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына, мәгариф, сәламәтлек саклау, физик культура һәм массакүләм спортка кагылган, каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыруга, муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле башка өлкәләре һәм муниципаль берәмлек халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан мөмкин булган максималь дәрәҗәдә уңайлы булуын исәпләү күрсәткечләренә кагылган муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешенең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре җыелмасын билгели.

1.3. Җирле нормативларда кеше тормышының уңай шартларын тәэмин итүнең минималь исәп-хисап күрсәткечләре Зәй муниципаль районының шәһәр төзелешен проектлау нормативларындагы кеше яшәеше өчен уңай шартлар белән тәэмин итүнең исәп-хисап күрсәткечләренә караганда түбәнрәк була алмый.

## II. Җирле нормативларны әзерләү һәм раслау тәртибе

2.1. Җирле нормативларны әзерләү Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә башкарыла.

2.2. Җирле нормативлар проектын әзерләү турында карарда билгеләнә:

- җирле нормативлар проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчә (алга таба - вәкаләтле орган);
- җирле нормативлар проектын әзерләү сроклары;
- кызыксынган затларның җирле нормативлар проекты буенча тәкъдимнәрен җибәрү һәм карау тәртибе;
- җирле нормативларны әзерләү буенча эшләрне оештыруның башка

мәсьәләләре.

2.3. Вәкаләтле орган:

1) җирле нормативлар проектын әзерләү буенча эшләрне оештыруны гамәлгә ашыра;

2) җирле нормативларны әзерләү буенча техник биремне эшли;

3) кызыксынган затлардан җирле нормативлар проекты буенча тәкъдимнәрне җыюны тәэмин итә;

4) район Советының җирле нормативларны раслау яки аларга үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

2.4. Җирле нормативлар проектын әзерләү турындагы карар, карар кабул ителгән көннән алып, Зәй муниципаль районының "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш.

2.5. Җирле нормативлар проекты расланырга кимендә ике ай кала интернет челтәрендә Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш.

2.6. Кызыксынган затлар җирле нормативлар проекты буенча үз тәкъдимнәрен тәкъдим итәргә хокуклы.

2.7. Җирле нормативларны әзерләү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, норматив техник документлар, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.8. Билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән җирле нормативлар проекты килештерелергә тиеш:

- Зәй муниципаль районының Башкарма комитеты белән;
- Зәй муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән

2.9. Җирле нормативлар проектын Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре, әлеге нигезләмәнең 2.8 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм ведомстволар белән килештерү җирле нормативлар проектын килештерүгә җибәргәннән соң утыз көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.10. Җирле нормативлар проектын килештерү нәтиҗәләре әзерләнгән проектның техник биремгә, норматив техник документларга, Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына туры килүе турында Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты бәяләмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

2.11. Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты әлеге нигезләмәнең 2.10 пунктында күрсәтелгән бәяләмәне әзерләгәннән соң биш көн эчендә җирле нормативларның килештерелгән проектын Зәй муниципаль районы башлыгына Зәй муниципаль районы Советы каравына кертү турында карар кабул итү өчен җибәрә.

2.12. Зәй муниципаль районы Советы җирле нормативлар проектын раслый. Раслау турындагы карар "Интернет" челтәрендә Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә аны кабул иткән көннән алып өч көн эчендә бастырып чыгарылырга тиеш.

2.13. Раслау турында карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә вәкаләтле орган күрсәтелгән карарны, расланган җирле нормативлар кушымтасы белән, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.1 статьясы 2 пункты нигезендә региональ әһәмияттәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча шәһәр төзелешен проектлау нормативларын системалаштыруны тәэмин итү өчен, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органына җибәрә.

2.14. Вәкаләтле орган расланган җирле нормативларны территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында күрсәтелгән нормативлар расланган көннән алып биш көннән дә артмаган срокта урнаштыруны тәэмин итә.

2.15. Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау өчен әлеге нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гамәл.